**Р Е С П У Б Л И К А
Т А Т А Р С Т А Н**

**С О В Е Т  М И Ч А Н С К О Г О
С Е Л Ь С К О Г О  П О С Е Л Е Н И Я
С А Б И Н С К О Г О
М У Н И Ц И П А Л Ь Н О Г О  Р А Й О Н А**

**422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31**

**Т А Т А Р С Т А Н
Р Е С П У Б Л И К А С Ы**

**С А Б А  М У Н И Ц И П А Л Ь
Р А Й О Н Ы  М И Ч Э Н  А В Ы Л
Җ И Р Л Е Г Е  С О В Е Т Ы**

**422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,**
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы, 12 йорт
**тел. (84362) 42-3-31**

e-mail: mich.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.09.2019 № 24

Татарстан Республикасы Мичән авыл җирлеге Советының 2009 елның 25 декабрендәге 16 номерлы «Мичән авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында " карары белән расланган Мичән авыл җирлеге Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 10.09.2009 ел, № 02-01-20-19 хаты, Мичән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Мичән авыл җирлеге Советының 2009 елның 25 декабрендә кабул ителгән «Мичән авыл җирлеге Советы регламентын раслау турында» гы 16 нче номерлы карары белән расланган Мичән авыл җирлеге Советы Регламентына үзгәрешләр кертергә:

1.1. Регламентның 6 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

"34.1 Статья.

1. Мичән авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук законнар, Мичән авыл җирлеге Уставы белән вәкаләтле башка вазыйфаи затлар Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Мичән авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Башкарма комитет хезмәткәрләре Совет тарафыннан алар карамагына караган мәсьәләләрне караганда ачык утырышларда катнашырга хокуклы.
4. Әгәр бу тәкъдим депутатларның гомуми санынннан абсолют күпчелеге тарафыннан кабул ителсә, Совет утырышында җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Таләп, кимендә өч көннән дә соңга калмыйча, утырышка кадәр, Совет рәисе тарафыннан, утырышны уздыру вакытын, урынын күрсәтеп, чакырылган вазыйфаи затның белешмәләренә, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаи затның Совет утырышына чакыртыла торган мәсьәләсенә җиткерелә.
5. Совет рәисе утырыш ачылыр алдыннан утырышта катнашучы Совет депутатлары булмаган затлар турында хәбәр итә.
6. Утырышта катнашучылар һәм чакырылган затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел (чыгыш ясарга, гариза ясарга, хуплау яисә канәгатьсезлек белдерергә).
7. Совет карары буенча чакырылган затларга әлеге «регламент»кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.
3.Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Мичән авыл җирлеге башлыгы: А.Ә.Гәрәев